СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(84378) -3-54-22
факс: 8-(84378) -3-54-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(84378) -3-54-22
факс: 8-(84378) -3-54-22

2019 елның 5 ноябрендәге 51 номерлы

КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлеге составына керүче Түбән Кармачи торак пунктындагы гражданнар җыены карары.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Александровка авыл җирлеге составына керүче Түбән Кармачи торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Түбән Кармачи торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Түбән Кармачи торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту.

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:_________________ И.А.Бандурова

Башлык - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-
Александровка авыл җирлеге Советы рәисе _________________ И.А.Бандурова